| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**<br>**ул. Ленина,д.43в,с.Янурусово,423370**<br>**Телефон:(85559 ) 4-10-19** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**<br>**Ленин урамы, 43в йорт, Янурыс авылы, 423370**<br>**Телефон: :(85559) 4 –10-19** |

**ОГРН 1061687002574 ИНН/КПП 1636005486/163601001**

# КАРАР

**12.01.2015 ел** **Янурыс авылы** **№ 1**

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Янурыс авыл җирлеге Уставының 11,12 ст., Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"Сез 2015 елда Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлек студентларыннан тыш , түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү ;
- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру(урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп);
- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту .

«ӘЙЕ ЮК» .

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Янурыс авыл җирлеге
Җитәкчесе А.Ә.Мөхәммәдиева